ГЛАВА ОМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление | Карар

“21” октября 2020 г. | № 7

Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Рагозино торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыенында катнашучы затларны теркәү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Омар авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" гы 2019 елның 14 октябрендәге 2-51 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Омар авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе Кочурова Роза Николаевнаны Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Рагозино торак пунктында 2020 елның 19 ноябре гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенында катнашучы сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен җаваплы итеп билгеләргә.
2. Гражданнар җыенында катнашучы затларны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә теркәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге башлыгы: Л.Н.Хәбибуллин